АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423740, село Актаныш, проспект Ленина, дом 58, тел.3-44-40

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт, тел.3-44-40

# КАРАР

**№9** **«08» июнь 2021г**

«Инфраструктур үсеш бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләрен һәм хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. «Капиталь төзелеш объектына (шул исәптән төгәлләнмәгән) Актаныш авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан почта адресын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Актаныш авыл җирлеге башкарма комитетының 12 февраль 2013 елның № 9 карарын үз көчен югалткан дип таныргa.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Актаныш авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш авыл Башкарма комитеты җитәкчесе — Р.Р.Шәрипов